**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**УСАД АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422710, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Усад авылы, Совет ур.,41

**СОВЕТ УСАДСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422710, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Усады, ул.Советская, 41

Тел./факс: +7(84365) 72-2-75, e-mail: Usad.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**4 март 2019 ел** **№ 167**

# Усад авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы РФ Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Усад авыл җирлеге” Уставы белән эш йөртеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Теркәлгән Усад авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

Усад авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында”, 2017 елның 4 мартдәге 78 номерлы карарын;

Усад авыл җирлеге Советының “Усад авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында”, 2017 елның 4 мартдәге 78 номерлы карары белән расланган карарга үзгәрешләр кертү турында”, 2018 елның 17 августындагы 138 номерлы карарын.

3. Әлеге карар Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырылганнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
авыл җирлеге Башлыгы О.А.Фомин

Кушымта

РАСЛАНГАН:
ТР Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге Советы карары белән
04 март 2019 N 167

**Гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Усад авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турында әлеге Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Россия Федерациясе Коституциясе, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Усад авыл җирлеге” муниципаль бермәлеге (алга таба – Җирлек) Уставы нигезендә эшләп чыгарылган.

## 1 бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 статья. Төп төшенчәләр

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

гавами тыңлаулар - Җирлек халкының җирле үзидарә органнары тарафыннан Җирлекнең җирле әһәмияткә ия мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актлар проектларын халык алдында фикер алышып кабул ителә торган халыкның хокукларын тормышка ашыру формасы, шулай ук федераль законнар, әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән мәсьәләләр буенча фикер алышу өчен;

инициатив төркем - гавами тыңлауларда катнашырга хокукы булган Россия Федерациясе гражданины яки гражданнар төркеме;

җәмәгатьчелек вәкиле - гавами тыңлауларда тикшерелә торган мәсьәлә буенча фикер алышуда, җәмәгать тыңлауларында катнашу хокукы булган физик зат, шул исәптән юридик затларның, берләшмәләрнең вәкилләре. Җәмәгатьчелек вәкилләренә хезмәт вазыйфалары буенча гавами тыңлауларга куелган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итүче җирле үзидарә органнары, яки дәүләт хакимияте вәкилләре, яки бушка булмаган килешү нигезендә аларның эшчәнлегендә катнашучы затлар керми;

гавами тыңлауларда катнашучылар - җирле үзидарә органнары һәм аларның вәкилләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, гавами тыңлаулар экспертлары, гавами

тыңлаулар үткәрү буенча оештыру комитеты әгъзалары;

гавами тыңлауларда чыгыш ясау хокукы булган катнашучылар – җирле үзидарә органнары аларның вәкилләре, әлеге Нигезләмәнең 6 статьясы белән билгеләнгән срокларда оештыру комитетына гавами тыңлаулар мәсьләләре буенча чыгыш ясауга үзләренең гаризаларын биргән җәмәгатьчелек вәкилләре;

оештыру комитеты – гавами тыңлауларны әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру эшләрен гамәлгә ашыручы Җирлекнең җирле үзидарә органнарыннан, Җирлек Советы депутатларыннан, җәмәгатьчелек һәм гражданнарның инициативалы теркемнәре вәкилләреннән формалашкан коллегиаль орган;

иҗтимагый фикер алышулар – җәмәгать контроле максатларында кулланылган иҗтимагый әһәмияттәге мәсьәләләр , шулай ук җирле үзидарә органнары карарлары проектлары буенча халык алдында тиешле карар мәнфәгатьләренә кагылган җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның вәкаләтле затларының, гражданнар һәм иҗтимагый берләшмәләр вәкилләренең катнашуын да кертеп фикер алышу.

гавами тыңлаулар эксперты – гавами тыңлаулар мәсьәләләре буенча махсус белемнәре булган һәм бу статуста вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнгән зат. Эксперт язмача рәвештә ачык тыңлаулар мәсьәләләре буенча рекомендацияләр тәкъдим итә һәм аларны аргументацияләү өчен, фикер алышуларда катнаша.

**2 статья. Гавами тыңлаулар уздыруның максатлары**

Гавами тыңлаулар түбәндәге максатларда үткәрелә:

Җирлекнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча Җирлек халкы катнашында мәҗбүри тәртиптә гавами тыңлауларга чыгарылган муниципаль хокукый актларның проектларын тикшерү;

гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр буенча җәмәгать фикерен ачыклау һәм исәпкә алу.

гавами тыңлауларны әзерләү, уздыру һәм нәтиҗәләрен билгеләү экспертларның ачыклыгы, хәбәрдарлыгы, иреклелеге, бәйсезлеге принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**3 статья. Гавами тыңлауларга чыгарылучы мәсьәләләр**

1. Гавами тыңлаулар җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча үткәрелә. Ачык тыңлаулар нәтиҗәсе җирле үзидарә органнары өчен тәкъдим рәвешендә була.

2. Гавами тыңлауларга мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1) Россия Федерациясе Конституциясе нигезләмәләрен, федераль законнарын, Татарстан Республикасы Конституциясен яки законнарын төгәл итеп яңадан кабул итү формасында, Уставны шушы норматив хокукый актлар халәтенә китерү максатларында, Уставка үзгәрешләр кертелгән очрактан кала, Җирлекнең Устав проектына (алга таба - Устав), шулай ук Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү

турындагы Җирлек Советы Карары проекты.

2) җирле бюджет проекты һәм аның үтәлеше турында хисап (отчет);

3) Җирлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясе проекты;

4) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оешмасының гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә, Җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре турында мәсьәләләре Җирлек халкының тавыш бирү юлы белән яки гражданнар жыеннарында ризалыгы таләп ителгән очраклардан кала;

5) генераль план проекты, җирдән файдалану кагыйдәләре һәм төзелешләр проекты, территорияне планлаштыру проекты, территорияне ызанлау проекты, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проекты, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне куздә тоткан проект, җир участогын яки капиталь төзелеш обьектын куллануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү карары проекты, рөхсәт ителгән тезелешнең чикле параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карары проекты, капиталь төзелеш объектлары реконструкцияләре, расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән кулланылышының бер төрен шундый башка кулланылыш төренә үзгәртү соратулары буенча иҗтимагый фикер алышулар яки гавами тыңлаулар уздырыла, аларны оештыру һәм уздыру тәртибе авыл җирле уставы һәм (яки) җирлек Советының норматив хокукый акты нигезендә шәһәр төзелеше турында законнар нигезләмәләре нигезендә билгеләнелә;

6) гавами сервитутлар билгеләү мәсьәләләре;

7) җылылык белән тәэмин итү схемасы проекты;

8) федераль законлылык тарафыннан билгеләнгән башка мәсьәләләр;

3. Һәр мәсьәлә буенча төрле яклап һәм тулысынча фикер алышуга каршылык булмаган очракта, берничә мәсьәлә буенча бер ук вакытта гавами тыңлаулар үткәрергә рөхсәт ителә.

4. Россия Федерациясе законнары тарафыннан башка финанслау билгеләнмәгән булса, гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру җирле бюджет хисабына финанслана.

**4 статья. Гавами тыңлауларның инициаторлары**

Гавами тыңлаулар Регламент нигезендә, Җирлек Советы, (алга таба - Совет), Җирлек башлыгы (алга таба – Башлык), халык инициативасы буенча үткәрелә.

Гавами тыңлаулар үткәрү буенча халык инициативасы 15 кешедән дә ким булмаган, 18 яше тулган гражданнар төркеменнән булырга мөмкин .

## 2 бүлек. ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАРНЫ БИЛГЕЛӘҮ

**5 статья. Гавами тыңлауларны билгеләү**

1. Халык яки Совет инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар, Совет карары белән билгеләнә.

Башлык инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар, Җирлек Башлыгы карары белән билгеләнә.

Гавами тыңлаулар Россия Федерациясе законнары тарафыннан җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кергән мәсьәләләр буенча үткәрелә.

2. Гавами тыңлаулар уздыру турында халыкның инициативасын белдерү өчен һәм инициативаны күтәреп алу буенча халыктан имзалар җыю өчен 10 кешедән дә ким булмаган инициатив төркем формалаша.

2.1. Инициатив төркем Советка тәкъдим итә:

- 1 нче кушымта нигезендә, гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзаланган форма буенча, гавами тыңлаулар мәсьәләсен күрсәтеп, гавами тыңлауларны билгеләү турындагы гариза һәм аларны уздыруның мөкимлеген дәлилләү;

- муниципаль акт проекты (гавами тыңлауларга карауга аны чыгарган вакытта);

- муниципаль хокукый актның максатларын һәм төп нигезләмәләрен, аны кабул итү мөмкинлеген дәлилләгән анлатма язуы (каралу өчен гавами тыңлауларга кертелгән очракта);

- финанс-икътисадый нигезләү (гамәлгә ашыру өчен өстәмә матди һәм башка чыгымнар таләп итә торган муниципаль хокукый актны гавами тыңлауларга карау өчен куелган очракта);

- 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча, гражданнарның инициатив төркеме исемлеге;

- гражданнарның инициатив төркемен төзү турында карар кабул ителгән җыелыш беркетмәсе;

- битләр санын, шулай ук муниципаль хокукый акт проекты докладчысын күрсәтеп инициатив төркем тарафыннан тәкъдим ителгән, исемлекле инициатив төркем вәкаләтле вәкиленең вәкиле тарафыннан имзаланган бергә теркәп җибәрелә торган (сопроводительное) хат (муниципаль хокукый актны гавами тыңлауларга карау өчен куелган очракта).

Гариза һәм беркетмә рәислек итүче (гражданнар инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле) һәм инициатив төркем жыелышының сәркатибе тарафыннан имзаланган булырга тиеш.

2.2. Әгәр Советка бер үк вакытта әлеге статьяның 2.1 пунктчасында билгелеләнгән барлык документлар да тәкъдим ителгән булса, гариза бирелгән булып санала.

2.3. Советка гариза һәм аңа беркетелгән документлар кергән көннән алып 30 көнлек срок эчендә, гавами тыңлаулары уздыруны хуплаган халыкның, әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушытасындагы форма буенча Җирлектә яшәүче 18 яшь тулган халыкның гомуми саныннан 30 кешедән дә ким булмаган Җирлектә яшәүчеләрнең

имзалары инициатив төркем тарафыннан җыелган һәм тапшырылган булырга тиеш.

Имзалар Советка гавами тыңлаулар уздыру инициативасын тәкъдим итү турындагы гариза биргән көннән алып җыелырга мөмкин. Кул кую кәгазенә кул куелмаган ысул яки карандаш белән мәгълүматлар кертергә рөхсәт ителми. Гражданнар турындагы һәм даталарда тиешле мәгълүматлардаге төзәтүләрне язылу кәгазенә кертү һәм раслау имзалары, шуңа бәйле рәвештә, гражданнар һәм имзаларны җыючылар тарафыннан килешенгән булырга тиеш.

2.4. Язылу кәгазьләре тапшырылганнан алып, 10 көн эчендә Совет эшче төркем төзи һәм язылу кәгазьләрендә тәкъдим ителгән мәгълүматларны тикшерү уздыра.

Кул кую кәгазьләрендәге имзаларны һәм мәгълүматларны тикшерү нәтиҗәләре буенча, имза хакыйкый яисә хакыйкый түгел дип танылa ала. Әлеге Нигезләмә нигезендә Әлеге имзалар хакыйкый түгел дип билгеләнмәгән очракта хакыйкый була.

Хакыйкый булмаган имзалар яки имзалар җыю тәртибен бозып җыелган һәм (яки) тутырылган язылу кәгазе дип танылa:

1) имзалар җыю чорыннан тыш җыелган имзалар;

2) 18 яшькә җитмәгән Җирлектә яшәүче халыкның имзалары;

3) кул кую кәгазенә үз кулы белән үз имзасын кую датасын күрсәтмәгән гражданнарның имзасы;

4) кул куелмаган ысул яки карандаш белән мәгълүматлар кертелгән имзалар;

5) гражданнар турындагы һәм даталарда тиешле мәгълүматлардагы төзәтүләрне язылу кәгазенә кертү һәм раслау имзалары (ул төзәтүләр гражданнар һәм имзаларны җыючылар тарафыннан махсус килешенмәгән очракта);

6) кул кую кәгазендәге барлык имзалар әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтадагы таләпләренә туры килми.

Тикшерү нәтиҗәләре кул кую кәгазьләренең тикшерү беркетмәсе белән рәсмиләштерелә (4 нче кушымта).

2.5. Советның чираттагы утырышында, кул кую кәгазьләре кергән көннән 15 көн вакыт дәверендә, гавами тыңлаулар билгеләү турындагы карар яисә гавами тыңлаулар турындагы гаризаны кире кагу карары кабул ителә, әгәр:

1) гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәләләр җирле үзидарә органнары компетенциясенә кермәсә (әлеге Нигезләмәнең 3 нче искәрмәсендәге очрактан кала);

2) гавами тыңлауларны уздыру турындагы халык инициативасын алга чыгару өчен тәкъдим ителгән хакыйкый имзалар саны гына җитми;

3) инициативасыны чыгару тәртибе үтәлмәгән;

4) каралырга тәкъдим ителгән муниципаль норматив хокукый акт проекты Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституция законнарына, федераль законнарга, башка норматив хокукый актларга туры килми;

5) әлеге мәсьәлә чыгарылган тыңлаулар уздырылган датадан соң бер елдан кимрәк вакыт узган.

2.6. Гавами тыңлаулар билгеләү турындагы гаризадан тайпылу, гавами тыңлауларны билгеләү өчен, баш тарту китереп чыгарган җитешсезлекләрне бетергән очракта, инициатив төркем тарафыннан документларны кабат кертүгә каршылык булып тормый.

2.7. Гавами тыңлауларны билгеләү мәсьәләсе Совет тарафыннан Совет регламенты нигезендә карала.

2.8. Гавами тыңлаулар билгеләү турындагы гаризадан тайпылу булган очракта, Совет, эшче көннәрдә хисапланган 5 көнлек срокта, гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле адресына язма дәлилләнгән хәбәрнамә җибәрә (юллый).

3. Гавами тыңлауларны билгеләүче Совет, Башлык, тыңлауларның мәсьәләсе, вакыты, һәм үткәрү урыны, оештыру комитеты составы, исәпкә алу буенча тәкьдимнәр тәртибе һәм ачык тыңлауларга чыгарылган муниципаль хокукый акт проекты турында фикер алышуда гражданнарның катнашуы турында мәгълүматле тиешле муниципаль актлар кабул итәләр.

Гавами тыңлауларны үткәрү датасы, федераль законнар, Устав һәм әлеге Нигезләмә тарафыннан башка билгеләү булмаганда, ачык тыңлаулар билгеләү турындагы муниципаль хокукый акт кабул ителгән көннән 30 көнлек срокта билгеләнә.

**6 статья. Гавами тыңлаулар турында мәгълүмат бирү**

1. Җирлек халкына гавами тыңлаулар турында хәбәр бирү, тыңлаулар уздырган көнгә кадәр эш көннәрдә хисапланган 10 көнлек дәвердә, (федераль законнар, Устав һәм әлеге Нигезләмә тарафыннан башкасы күздә тотылмаса), гавами тыңлаулар билгеләү турындагы муниципаль хокукый акт турында фикер алышуның проект-кушымтасы белән муниципаль хокукый акт билгеләү турында игълан итү (аны карау өчен ачык тыңлауларга керткән очракта), массакүләм мәгълумат чараларында, рәсми сайтта һәм (яки) башка мәгълүмат системалары өчен мәгълүмат стендында бастырып чыгару юлы белән башкарыла.

1.1 Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре массакүләм мәгълүмат чараларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында һәм (яки) башка мәгълүмат системалары һәм мәгълүмат стендларында басылып чыга.

Мәгълүмати стендлар яхшы күренә торган урыннарда, мәгълүмат кулланучыларның күрә алу мөмкинлекләрен тәэмин итүне исәпкә алып урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларны урнаштыру, эргономика таләпләренә туры китереп, мәгълүмат кулланучының озак вакытлар уңайсыз халәттә тору кирәклеген гамәлдән чыгарып гамәлгә ашырылырга тиеш.

Мәгълүмати стендларны төсле рәвештә бизәү эстетик таләпләргә туры килергә тиеш. Мәгълүмати стендлар, мәгълүмати битләр сыярлык А4 форматлы кесәләр белән тулыландырылырга мөмкин.

2. Гавами тыңлауларында яки гавами фикер алышуларында каралырга тиешле проект экспозициясен үткәрү мәйданы, шулай ук проект экспозициясенә

килүчеләргә консультация бирү вакыты, килештерү буенча гавами тыңлаулар яисә җәмәгать фикер алышуларын үткәрү турында хәбәр итүгә кертелә.

Экспозиция эшләгән чорда килүчеләр өчен консультацияләр, проект турында басма мәгълүмати материаллар тарату оештырыла. Экспозициягә килүчеләр тикшерелүче проектка, мәсьәләгә карата үзләренең тәкъдимнәрен, кисәтүләрен язмача рәвештә экспозициягә килүчеләрнең исәбен алу һәм тәкъдимнәр, искәрмәләр язу өчен тиешле китапка (журналга) кертергә хокуклы.

Экспозиция проектында күрсәтелә:

- проект;
- проектка анлатмалы язма;
- Россия Федерациясенең законнары һәм башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасының законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә алынган документлар килештерүләре күчермәләре;
- гавами тыңлаулар яисә проект буенча гавами фикер алышуны уздыру турында мәгълүмати хәбәр итүне бастырып чыгару күчермәсе, массакүләм мәгълүмат чарасы турында мәгълүматларны күрсәтеп;
- тикшерелүче проект буенча гражданнарны хәбәрләү максатыннан башка мәгълүмати һәм демонстрацион материаллар тапшырыла, проектның оештыручысы андый материаллар белән тәэмин иткән очракта;

## 3 бүлек. ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАРНЫ ӘЗЕРЛӘҮ ҺӘМ УЗДЫРУ

### 7 статья. Гавами тыңлауларны әзерләүне оештыру һәм уздыру

1. Гавами тыңлаулар Җирлектә яшәүче халык өчен уңайлы вакытта үткәрелә (гавами тыңлауларны эш көне булмаган вакытларда 11.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә яисә эш көннәрендә 17.00 сәгатьтән башлап 22.00 сәгатьтән дә соңга калмыйча үткәрергә киңәш ителә).

2. Гавами тыңлауларны билгеләү турында карар кабул иткән җирле үзидарә органынын оештыру комитеты Җирлекнең депутатлары, Җирлек Башкарма комитеты хезмәткәрләре, иҗтимагый оешмалар вәкилләреннән, гражданнарның инициатив төркемнәреннән торган (әгәр гавами тыңлауларның уздыру инициаторы булып гражданнарның инициатив төркеме чыгыш ясаса) саны 5 кешедән ким булмаган оештыру комитеты формалаштыра. Оештыру комитеты, формалашканнан соң 3 көннән дә соңга калмыйча, беренче утырышта үз составыннан рәис, рәис урынбасары һәм сәркатиб сайлый. Оештыру комитеты, утырышта әгъзаларының яртысыннан артыгы булганда, карарлар кабул итәргә хокуклы.

Оештыру комитеты катнашырга теләүчеләрнең тыңлаулар үткәрелә торган бинага каршылыксыз керү мөмкинлеген тәэмин итәргә бурычлы.

Оештыру комитеты тыңлаулар уздырыла торган көнне гавами тыңлауларда катнашучыларны теркәүне оештыра.

3. Җәмәгать тыңлауларында рәислек итүче булып оештыру комитеты рәисе тора. Рәислек итүче гавами тыңлауларны ача, тыңлаулар буенча сорау (сораулар), тыңлауларны үткәрү тәртибенә карата тәкъдимнәрне яңгырата, үзе, сәркатиб һәм экспертлар белән таныштыра, тыңлаулар үткәрүнең инициаторларын атый.

Оештыру комитеты сәркатибе ачык тыңлаулар беркетмәсен алып бара.

4. Рәислек итүче фикер алышу буенча үткәрелә торган мәсьәләне игълан итә һәм гавами тыңлаулар үткәрү инициаторлары белән вәкаләтле вәкиллек итүче затка, экспертларга, шулай ук чыгыш ясау хокукына ия булган гавами тыңлауларда катнашучыларга сүз бирә. Чыгышлар чираты оештыру комитеты тарафыннан теркәлгән гаризалар бирелү чираты белән билгеләнә.

5. Тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән экспертлар, үзләренең рекомендацияләрен алырга һәм (яки) гавами тыңлауларның башка катнашучылары тарафыннан тәкъдим ителгән тәкъдимнәргә кушылырга хокуклы.

Фикер алышу нәтиҗәләре буенча җирле әһәмияткә ия, гавами тыңлауларга чыгарылган сорауны (сорауларны) чишү буенча бердәм тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр исемлеге төзелә (гавами тыңлауларда катнашучылар алып ташлаган тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр искәрмә булып тора).

6. Рәислек итүче, тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр белән йомгаклау документы төзегәннән соң, җирле әһәмияткә ия мәсьәләне хәл итунең (сораулар) йомгаклау вариантын катнашучылар тавыш бирүенә куя. Гавами тыңлауларда мәсьәләне хәл итү ачык тавыш бирү юлы белән теркәлгән тыңлауларында катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тыңлауларда катнашучы һәр кеше бер тавышка ия, аны ул җирле әһәмияттәге мәсьәләнең тәкъдим ителгән карары өчен (аңа каршы яки тавыш бирүдән тыелып торам дип) бирә. Тавыш биру нәтиҗәләре беркетмәгә теркәлә (кертелә). Беркетмә гавами тыңлауларда рәислек итүче һәм сәркатиб тарафыннан имзалана.

7. Гавами тыңлаулар беркетмәсе нигезендә, гавами тыңлауларны уздырганнан соң эш көннәре белән хисапланган 3 көнлек дәвер эчендә, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә төзелә (6 нчы кушымта), анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) гавами тыңлауларга чыгарылган сорау (сораулар);
2) гавами тыңлауларны үткәрүнең инициаторы (башлап йөрүчесе);
3) гавами тыңлауларны билгеләү турындагы хокукый актның атамасы, датасы, номеры, шулай ук аны бастырып чыгару (халыкка житкерү) датасы;
4) гавами тыңлауларны үткәрүнең датасы, вакыты һәм үткәрү урыны;
5) гавами тыңлауларны үткәрүче оештыру комитеты;
6) гавами тыңлауларда катнашучылар, шул исәптән чыгыш ясарга хокук алучылар турында мәгълүмат;
7) гавами тыңлауларга чыгарылган җирле әһәмияттәге сорауны (сорауларны) чишү буенча тәкьдимнәрнең һәм рекомендацияләрнең бердәм исемлеге, гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан алып ташланган тәкьдимнәр һәм рекомендацияләрдән кала;
8) җирле әһәмияткә ия мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты;
9) гавами тыңлауларда катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре күрсәтелә.

8. Гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турындагы бәяләмә оештыру комитетының рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалана һәм гавами тыңлауларны уздырганнан соң эш көннәре белән хисапланган 3 көнлек дәвер эчендә

бастырылырга (халыкка житкерелергә) тиеш була.

9. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә җирле үзидарә органы, мәсьәләләрне һәм сорауларны кабул итү, гавами тыңлауларга чыгару буенча җаваплы кеше тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш. Бәяләмә нәтиҗәләре, гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турындагы бәяләмәне җирле үзидарә органы вәкаләтле вәкиле караганнан соң эш көннәре белән хисапланган 3 көнлек дәвер эчендә, мәҗбүри тәртиптә гавами тыңлаулар инициаторлары тарафыннан муниципаль берәмлек халкына бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән житкерелә.

10. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы бәяләмә, Россия Федерациясе законнары тарафыннан билгеләнгән очраклардан тыш, тәкьдим рәвешендә була.

## 4 бүлек. МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕК УСТАВЫ ПРОЕКТЫ, УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДАГЫ СОВЕТ КАРАРЫ ПРОЕКТЫ, ҖИРЛЕ БЮДЖЕТ ПРОЕКТЫ ҺӘМ АНЫҢ ҮТӘЛЕШЕ БУЕНЧА ХИСАП, МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКНЕ ҮЗГӘРТЕП КОРУ МӘСЬӘЛӘСЕ , МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРНЕҢ ГЕНЕРАЛЬ ПЛАННАРЫ ПРОЕКТЛАРЫ БУЕНЧА ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАРНЫ ОЕШТЫРУ ҺӘМ УЗДЫРУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

### 8 статья. Җирлек Уставы проектын һәм Уставка үзгәрешләр кертү турында Совет карары проектын җәмәгать тыңлауларында карау үзенчәлекләре

1. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы Устав проекты һәм Совет карары проекты, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законында һәм Уставта каралаган үзенчәлекләрне исәпкә алып, гавами тыңлауларда карала.

2. Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Устав проекты һәм Совет карары проекты Совет тарафыннан аны кабул итү турындагы мәсьәләне карауга 30 көннән дә кичекмичә рәсми бастырылырга (халыкка житкерелергә) тиеш. Бер үк вакытта күрсәтелгән проект буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе, анын буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе, шулай ук проект буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында Совет карары басылып чыга.

Уставка Россия Федерациясе Конституциясе Нигезләмәләрен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы Конституциясен, Татарстан Республикасы законнарын төгәл тәңгәл китерү кебек формадагы үзгәрешләре кертелгәндә, Уставны шушы норматив хокукый актлар халәтенә китерү максатларында, Совет карарына, Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук анын буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе турындагы проект буенча тәкъдимнәрнең исәп тәртибен рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.

3. Устав проекты яки Совет карары проекты буенча Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы гавами тыңлаулар, күрсәтелгән проектлар бастырып

чыгарылганнан соң, кимендә 10 көн дигәндә, Устав тарафыннан билгеләнгән вакытта үткәрелә.

4. Муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт Советы карары проекты яки Устав проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

**9 статья. Гавами тыңлауларда җирле бюджет проектын һәм аның үтәлеше буенча хисап бирү үзенчәлекләрен карау**

1. Җирле бюджет проекты һәм анын үтәлеше турындагы еллык хисап гавами тыңлауларда Россия Федерациясе Бюджет кодексы, башка федераль законнар, Устав, Җирлек бюджет процессы турында Нигезләмә тарафыннан каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып карала.

2. Җирле бюджет проекты буенча гавами тыңлауларны һәм җирле бюджет үтәлеше турындагы хисапны гамәлгә ашыручы орган булып оештыру комитеты тора. Җирле бюджет проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турындагы карарны кабул итүче һәм җирле бюджет үтәлеше турындагы хисапны гамәлгә ашыручы орган булып муниципаль берәмлек Советы тора.

3. Җирле бюджет проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында, җирле бюджет үтәлеше турындагы отчёт буенча карарлар, кабул ителгәннән соң 10 көнлек срокта бастырылырга тиеш.

4. Җирле бюджет проекты буенча гавами тыңлаулар, җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап (җирле бюджет үтәлеше турындагы хисап) җирле бюджет проекты бастырып чыгарылганнан соң, ким дигәндә, 15 календарь көннән соң үткәрелә.

**10 статья. Гавами тыңлауларда муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проектын карау үзенчәлекләре**

Муниципаль берәмлекнең соңиаль-икътисади үсеш стратегиясе проектларына кагылышлы мәсьәләләр, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында”, 2014 елның 28 нче июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон тарафыннан каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып гавами тыңлауларга чыгарыла.

**11 статья. Муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәләне гавами тыңлауларда карау үзенчәлекләре**

1. Муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәлә буенча гавами тыңлаулар “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясында каралган очракларда үткәрелә, күрсәтелгән Федераль законның 13 статьясы 5 бүлегеннән кала.

2. Муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәләләр буенча

гавами тыңлаулар үткәрү буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

**12 статья. Иҗтимагый фикер алышуларда, гавами тыңлауларда муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру документлары проектлары буенча мәсьәләләрне карау үзенчәлекләре**

Генераль планнар проектларына, җирдән файдалану һәм төзелеш проектларына, территорияләрне планлаштыру проектларына, территорияне ызанлау проектларына, территорияләрне төзекләндерү проектларына, алда курсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күз алдында тотучы проектларга, җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын кулланунын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектларына, рөхсәт ителгән тезелешнең аерым параметрларыннан кире кагылуга рөхсәт бирү карары проектларына, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә, расланган җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда, җир кишәрлеген һәм капиталь төзелеш объектын кулланунын рөхсәт ителгән бер төрен башка шундый ук куллану төренә кагылган мәсьәләләр, Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы тарафыннан билгеләнгән нигезләмәләрен исәпкә алып, шулай ук иҗтимагый фикер алышуга чыгарыла ала.

Жирлекләрнең генераль планнарының проектлары буенча җәмәгать фикер алышуына, гавами тыңлауларны оештыруның һәм уздыруның үзенчәлекләре Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексының 28 статьясында китерелгән.

Жирлекләрнең генераль планнарына, үзгәрешләр кертүне күздә тоткан җирлекләрнең генераль планнары (алга таба – иҗтимагый фикер алышу яки гавами тыңлаулар) буенча җәмәгать фикер алышулары, гавами тыңлаулар муниципаль берәмлекнең һәр торак пунктында үткәрелә.

Иҗтимагый фикер алышуда яки гавами тыңлауларда катнашучыларны, иҗтимагый фикер алышуда яки гавами тыңлауларда катнашу өчен тигез мөмкинлекләр белән тәэмин итүү максатларында, иҗтимагый фикер алышу яки гавами тыңлаулар уздырганда торак пункт территориясе өлешләргә буленгән булырга мөмкин .

Иҗтимагый фикер алышуларның яки гавами тыңлауларның вакыты, аларны үткәрү турында муниципаль берәмлек халкына хәбәр итүдән алып иҗтимагый фикер алышуларның яки гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бастырып чыгаруга кадәр Җирлекнең уставы һәм (яки) Җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә һәм бер айдан кимрәк, өч айдан артыграк була алмый.

Башкарма комитет җитәкчесе, иҗтимагый фикер алышуларның яки гавами тыңлауларның нәтиҗәләрен исәпкә алып, түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) генераль планның проекты белән ризалыгы һәм аны Җирлек Советына жибәрү турында;

2) генераль планнын проектын кире кагу һәм аны эшләп бетерүгә жибәрү.

**13 статья. Җәмгыять сервитутларын билгеләү буенча гавами тыңлаулар уздыруның үзенчәлекләре**

1. Җәмгыять сервитутларын билгеләү буенча гавами тыңлауларда катнашу хокукына территориясендә җәмгыять сервитутлары билгеләү каралган Җирлектә даими яисә күп вакыт яшәүче, тыңлаулар үткәрү көненә 18 яше тулган һәр гражданин ия.

Гражданнарның гавами тыңлауларында катнашуы үз теләкләре белән башкарыла.

Гавами тыңлауларда Җирлек территориясендә урнашкан иҗтимагый берләшмәләр, барлык милек формаларының коммерциячел һәм коммерциячел булмаган оешмалары катнашучылар була ала.

2. Гавами тыңлаулар 13 статьяның 1 пунктында курсәтелгәнчә, вәкаләтле орган яки физик һәм юридик затларның инициативасы буенча үткәрелә.

Гавами тыңлауларны үткәрү буенча вәкаләтле орган булып оештыру комитеты тора.

3. Гавами тыңлауларны уздыру турында карар кабул ителгәннән соң 7 эш көне дәвамында вәкаләтле орган аларны үткәрү турында Җирлек муниципаль актларының публикациясе өчен билгеләнгән рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастыра.

Иҗтимагый тыңлаулар ачылыр алдыннан аларның катнашучыларын мәҗбүри рәвештә теркиләр:

юридик зат өчен – юридик затның тулы исемен, дәүләт теркәве мәгълүматлалын;

шәхси эшмәкәр өчен - исем-фамилиясен, әтисенеӊ исемен, шәхси эшмәкәр сыйфатында гражданинның һәм дәүләт теркәве мәгълүматларын;

физик затлар өчен - исем-фамилиясен, әтисенеӊ исемен, туган елын, яшәү урыны адресын курсәтеп, мәҗбүри теркәү үткәрелә.

4. Гавами тыңлауларның нәтиҗәсе аларны уздыруның датасы һәм урыны, катнашучылар һәм анда булганнарның саны, гавами тыңлауларның рәисенеӊ, сәркатибенеӊ фамилиясе, исеме, әтисенеӊ исеме, чыгышларның эчтәлеге, тавыш бирү нәтиҗәләре һәм кабул ителгән карарлар күрсәтелгән беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Беркетмә ике нөсхәдә төзелә һәм гавами тыңлауларның рәисе һәм сәркатибе тарафыннан имзалаштырыла. Беркетмәгә гавами тыңлауларда катнашучыларның исемлеге беркетелә.

5. Җәмгыять сервитутларын билгеләү буенча гавами тыңлауларның нәтиҗәләре вәкаләтле орган тарафыннан каралалар һәм җәмгыять сервитутларын билгеләү өчен мөмкин булган кирәкле документларга кушылалар.

Җәмгыять сервитутларын билгеләү буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе срогы - өч ел. Вәкаләтле орган житәкчесе жәмгыять сервитутларын билгеләү буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен саклау өчен жаваплы.

## 14 статья. Гавами тыңлауларда җылылык белән тәэмин итү схемаларының проектын карау үзенчәлекләре

Җылылык белән тәэмин итү схемаларының проекты буенча гавами тыңлаулар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Җылылык белән тәэмин итү схемаларына, аларны эшләү һәм раслау тәртибенә таләпләр турында”, 2012 елның 22 февралендәге карарының 154 номерлы карары нигезендә каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып үткәрелә.

1 нче кушымта
Гавами тыңлауларны (иҗтимагый
фикер алышулар) оештыру һәм
уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

**ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАР БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА
ГАРИЗА**

______ кеше санында инициатив төркем, исемлек теркәп бирелә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл жирлеге муниципаль берәмлеге халкының инициативасы буенча түбәндәге сораулар буенча гавами тыңлаулар билгеләргә тәкъдим итә:_________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Гавами тыңлаулар уздыруның мөмкинлеген дәлилләү:______________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________

Кушымта (фактта тәкъдим ителгән документлар күрсәтелә):
1) муниципаль хокукый акт проекты (кертелгән очракта);
2) аңлатма язуы;
3) финанс-икътисади нигезләү (гамәлгә ашыру өстәмә матди чыгымнар һәм башка чыгымнар таләп иткән муниципаль хокукый акт кертелгән очракта);
4) гражданнарның инициатив төркеме исемлеге;
5) гражданнарның инициатив төркемен төзү турында карар кабул ителгән җыелыш беркетмәсе;
6) бергә теркәп җибәрелә торган хат.

Гражданнарның инициатив төркеме вәкаләтле вәкиле _______________
______________________________________________________________________________
(имза) (Ф.И.О.)

Гражданнарның инициатив төркеме сәркатибе _____________ _______________
(имза) (Ф.И.О.)

2 нче кушымта
Гавами тыңлауларны (иҗтимагый
фикер алышулар) оештыру һәм
уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

## ИНИЦИАТИВ ТӨРКЕМ ӘГЪЗАЛАРЫ ИСЕМЛЕГЕ

| N т /б | Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме һәм туган елы (18 яшьтә – туган елы һәм ае) | Яшәү урыны адресы | Паспорт мәгълүматлары (шәхесне раслый торган документның сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгәнлеге) | Шәхси имза |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

Гражданнарнын инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле _______________
_______________ _______________________________________________
(имза) (Ф.И.О.)

3 нче кушымта
Гавами тыңлауларны (иҗтимагый
фикер алышулар) оештыру һәм
уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

**ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАРНЫҢ ЯЗЫЛУ КӘГАЗЕ**

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
_______________________________________________________ мәсьәләсе буенча

Без, түбәндә имза куючылар,____________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
мәсьәләсе буенча "Биектау муниципаль районы Усад авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге халкының инициативасы буенча гавами тыңлаулар үткәрүне хуплыйбыз.

| N т/б | Фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | 18 яшьтәгеләргә – туган елы (өстәмә рәвештә туган көне һәм ае) | Яшәү урыны, адресы | Гражданинның паспортының яки паспортны алыштыручы башка документының сериясе һәм номеры | Шәхси имза |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Язылу кәгазен таныклыйм:_____________________________________________
________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, гражданның паспортының яки паспортны алыштыручы документының сериясе һәм номеры (аңа биргән органның исемен яки кодын курсәтеп), имза җыючы затның яшәү урыны, имзасы һәм аны кертү датасы).

Гражданнарның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле _______________
________________ ____________________________________________________
(имза) (Ф.И.О.)

4 нче кушымта

Гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышулар) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

**ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАРНЫҢ ЯЗЫЛУ КӘГАЗЕН ТИКШЕРҮ БЕРКЕТМӘСЕ**

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
__________________________________________________________ мәсьәләсе буенча:

"Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Усад авыл жирлеге" муниципаль берәмлеге Советына гавами тыңлаулар уздыруны хуплаган гражданнарның тәкьдим ителгән имзалар саны

______________________________________________________________________________.

Сайлаучыларның имзалары тикшерелгән ____________, шуларның гамәлдә булмаган дип табылды:_________________ түбәндәге сәбәпләр буенча: _________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________;

Гамәлдә түгел дип табылган имзалар саны – ______________________________.

Советка фактта тәкьдим ителгән гамәлдә дип табылган имзаларның гомуми саны тәшкил итә _______________.

Эшче төркем җитәкчесе _________________ ___________________________
(имза) (Ф.И.О.)

Эшче төркем әгъзалары ______________________ ____________________________
(имза) (Ф.И.О.)

_________________ ___________________________________
(имза) (Ф.И.О.)

__________________________________________________

Гражданнарның инициатив төркеме вәкаләтле вәкиле ______________ _______________ ______________________________________________________________
(имза) (Ф.И.О.)

Гражданнарның инициатив төркеме сәркатибе_____________ ________________
(имза) (Ф.И.О.)

5 нче кушымта
Гавами тыңлауларны (иҗтимагый
фикер алышулар) оештыру һәм
уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

**ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАР БЕРКЕТМӘСЕ**

___________ ав. N _____ "____" _________ 20__ ел

Инициатива буенча гавами тыңлаулар:
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

билгеләнгән _____________________________________________ __________ N ____
(муниципаль хокукый акт)

______________________________________________________________________________
(муниципаль хокукый акт исеме)

бастырылган (халыкка җиткерелгән):___________________________________________

уздырылган ___________ ______________.___________________________ адресы буенча
(уздыру вакыты)

Оештыру комитеты: ____________________________________________________

Катнаштылар: ____________________________________________________

Рәислек итүче: ____________________________________________________

Сәркатиб: ____________________________________________________

Экспертлар: ____________________________________________________

Гавами тыңлауларда катнашучылар: (теркәлгән катнашучылар саны)
______________________________________________________________________

Гавами тыңлауларда булган катнашучылар:_______________________________________
(Ф.И.О.)

Тыңлаучылар:

1.________________________________________________________________
(Ф.И.О.)

2. ________________________________________________________________
(Ф.И.О.)

3. ________________________________________________________________
(Ф.И.О.)

Телдән һәм язма рәвештә кертелгән рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр саны, шул исәптән:

| N т /б | Рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр | Гариза бирүче |
|---|---|---|
| | | |

Гавами тыңлауларда рәислек итүче:_______________ ____________________________

(имза) (Ф.И.О)

Гавами тыңлауларның сәркатибе:____________________________

________________________________

4 нче кушымта
Гавами тыңлауларны (иҗтимагый
фикер алышулар) оештыру һәм
уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә

**ГАВАМИ ТЫҢЛАУЛАРНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ ТУРЫНДА БӘЯЛӘМӘ**

"___" _________ 20__ ел ____________ав.

Инициатива буенча гавами тыңлаулар: ________________________________________

билгеләнгән _________________________________________________________________

(муниципаль хокукый акт)

_____N _____ ________________________________________________________________

(муниципаль хокукый акт исеме)

бастырылган (халыкка җиткерелгән):____________________________________ уздырылган

______________________________________ _________________________________ адресы буенча

(уздыру вакыты)

Гавами тыңлауларга чыгарылган мәсьәлә (мәсьәләләр) _________________________________

Гавами тыңлаулар үткәрүнең инициаторы ___________________________________________

Гавами тыңлаулар үткәрү датасы, вакыты һәм урыны _________________________________

Гавами тыңлаулар үткәрүче оештыру комитеты ________________________________________

Гавами тыңлауларда катнашучылар турында, шул исәптән катнашырга хокук алганнар турында мәгълүмат____________________________________________________________

Гавами тыңлауларга чыгарылган җирле әһәмияткә ия мәсьәлә (мәсьәләләр) буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләрнең, бердәм исемлеге:

| Фикер алышуга чыгарылган мәсьәләләр | | Экспертларның һәм катнашучыларның тәкъдимнәре һәм киңәшләре | | Тәкъдимнәр, рекомендацияләр) кертелә хуплана) | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|
| N | Сорау | N | тәкъдим тексты | Катнашучы | |

| т /б | формулировкасы яки проект атамасы | т/б | | экспертының Ф.И.О. | |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | 1 .1 | | | |
| | | 1.2 | | | |
| 2 | | 2.1 | | | |
| | | 2.2 | | | |
| 3 | | 3.1 | | | |
| | | 3.2 | | | |

Җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүнең йомгаклау варианты: ______________________________

Гавами тыңлауларда катнашучыларнын тавыш бирү нәтиҗәләре:

яклап ______________________ (кеше)

каршы__________________ (кеше)

тыелып тордылар____________ (кеше)

Оештыру комитеты рәисе _______________________________

Оештыру комитеты сәркатибе ________________________________